ГЛАВА ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Таү өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“05” ноябрь 2019 ел | № 3

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Тауиле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тауиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Тауиле авылы , Нагорная урамы , 5а йорт адресы буенча урнашкан Тауиле авылының «Тауиле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасында 2019 нчы елның 20 нче ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегененең Тауиле авылында 1 нче кушымта нигезендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Тауиле авылы , Нагорная урамы , 5а адресы буенча урнашкан Тауиле авылының «Тауиле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасында 2019 нчы елның 21 нче ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегененең Тауиле авылында 2 нче кушымта нигезендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Тауиле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы

гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Һәлак булган солдатка куелган Тауиле авылындагы һәйкәлне ремонтлау ( төзелеш материалы сатып алу, дивар салу, язулы мәрмәр табличкалар сатып алу, солдат скульптурасы астында пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эш өчен түләү);)
- Тауиле авылына янгын гидрантлары җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Тауиле авылындагы су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру;
- Тауиле авылындагы юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитетына Тауиле авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

5. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге башлыгы: В.И.Иванов